ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2025 Балык Бистәсе штп. № 38пи

“2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру” муниципаль программасын раслау турында

Автомобиль транспортында аварияләрне һәм юл-транспорт һәлакәтләренең аяныч нәтиҗәләрен киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы юлларында хәрәкәтнең имин шартларына законлы хокукларының гарантияләрен арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, “Юл хәрәкәте иминлеге турында" 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге УП-1115 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. “2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру” (алга таба-Программа) муниципаль программасын расларга.

2. Программаның заказчысы – координаторы итеп Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләргә.

3. Программа чараларын тормышка ашыруны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.02.2025№ 38пи
карары белән расланган

**“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру”
муниципаль программасы**

Балык Бистәсе штп.
2025 ел

# ЭЧТӘЛЕК

Программа паспорты 4
I. Проблема характеристикасы 6
II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары 9
III. Программа чаралары исемлеге 9
IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү 10
V. Программаны тормышка ашыру механизмы 11

Кушымталар:

1 нче кушымта
Программа-максатчан ысул булмау шартларында аварияләрнең көтелгән күрсәткечләре

2 нче кушымта
Муниципаль программа күрсәткечләренә ирешүнең көтелгән динамикасы

3 нче кушымта
Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый үзаңын арттыруга һәм үз-үзләрен куркыныч тотуларны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар

4 нче кушымта
Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары

5 нче кушымта
«2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын җирле бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклардан юнәлешләр буенча финанслау күләмнәре

6 нчы кушымта
«2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын җирле бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына финанслау күләмнәре (статьялар буенча)

7 нче кушымта
Программаның заказчылары арасында "2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән акчаларны бүлү.

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген арттыру”
муниципаль программасы
ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" (алга таба-Программа) муниципаль программасы |
| Программны эшләүгә нигезләмә | Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы |
| Программа заказчысы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет) |
| Программаны эшләүчеләр | Район башкарма комитеты, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча). |
| Программаның координаторы һәм башкаручылары | Координатор: район Башкарма комитеты;<br>башкаручылары: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты (килешү буенча), “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУ, Балык Бистәсе районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча), «Татарстан Республикасы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы фәнни һәм белем бирү программаларын финанслау дирекциясе» ГКУ (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты-гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы юлларында куркынычсыз хәрәкәт итү шартларына законлы хокукларының гарантияләрен арттыру.<br>Максатка ирешү шарты булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:<br>-юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны кимү;<br>-зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү;<br>-юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен куркыныч тотуларын кисәтү һәм транспорт чараларын йөртүчеләрнең ышанычлылыгын арттыру;<br>-балаларның юл-транспорт һәлакәтләрендә имгәнүләрен киметү;<br>- транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү. |
| Мөһим максатчан күрсәткечләр һәм индикаторлар | Программаның мөһим күрсәткечләре һәм индикаторлары булып тора:<br>- юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә кешеләрнең һәлак булуын искәртү;<br>- социаль куркынычны киметү (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны, 100 мең кешегә);<br>-транспорт куркынычын киметү (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны, 10 мең транспорт чарасына). |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | Программа 2025 елга исәпләнгән. |
| Программаны финанслау чыганаклары һәм күләмнәре | Программа буенча финанслауның гомуми күләме 209 680,46 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>җирле бюджеттан-550 мең сум,<br>республика бюджетыннан-99 637,23 мең сум<br>муниципаль юл фондыннан-98 972,53 мең сум.<br>бюджеттан тыш чыганаклардан-11 070,8 мең сум, шулардан:<br>капиталь кертемнәр -204 130,46 мең сум,<br>башка ихтыяҗларга- 5 550 мең сум<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм реаль мөмкинлекләрдән чыгып төгәлләштерелергә тиеш. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | 2025 ел белән чагыштырганда программаның мөһим индикаторларының уңай күрсәткечләренә ирешү:<br>Транспорт һәм социаль хәтәрлекне, юл-транспорт һәлакәтләренең авырлыгын киметү;<br>юл-транспорт һәлакәтләре күп булган урыннар санын киметү;<br>балалар катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту органы системасы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе Программа чараларының үтәлешен контрольдә тота |

## I. ПРОБЛЕМА ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

2012 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә ЮХИДИ мәгълүматлары буенча 34 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, аларда 7 кеше һәлак булган һәм 48 кеше тән җәрәхәтләре алган.

2013 елның шул ук чорында 46 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 9 кеше һәлак булган һәм 63 кеше тән җәрәхәтләре алган.

2014 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 44 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, аларда 45 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 17 кеше һәлак булган.

2015 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 38 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, аларда 42 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 7 кеше һәлак булган.

2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 45 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, аларда 55 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 8 кеше һәлак булган.

2017 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 48 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, аларда 72 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 15 кеше һәлак булган.

2018 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 34 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, аларда 42 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 7 кеше һәлак булган.

2019 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 36 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 43 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 10 кеше һәлак булган.


2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 33 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, шуларда 50 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 5 кеше һәлак булган.

2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 30 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, шуларда 41 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 10 кеше һәлак булган.

2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 37 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, шуларда 43 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 5 кеше һәлак булган.

2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 24 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, шуларда 31 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 2 кеше һәлак булган.

2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы автомобиль юлларында 26 юл-транспорт һәлакате теркәлгән, шуларда 37 кеше тән җәрәхәтләре алган һәм 6 кеше һәлак булган.









Хәзерге юл-транспорт травматизмын анализлау күрсәткәнчә, юл-транспорт һәлакәтләре саны акрынлап кими бара.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның иң күп санлы һәм иң сакланмаган төркеме- җәяүлеләр.

Юл-транспорт һәлакәтләрен профилактикалау һәм кисәтү буенча күрелә торган чаралар юлларда авариялелек үсешен тоткарлауга җитәрлек дәрәҗәдә ярдәм итми. Юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча җәмгыять үсешенең хәзерге этабында үзгәрешләр булган социаль-икътисади шартлар белән каршылыкларга киләләр, аеруча мөһим каршылыкларга түбәндәгеләр керә:

- автомобиль юллары һәм транспорт чишелешләре инфраструктурасы үсеше юллардагы автотранспорт саны арту дәрәҗәсеннән шактый калыша ;

- автотранспорт предприятиеләренең шактый өлеше Бистә чигендә урнашкан. Шуңа бәйле рәвештә, Балык Бистәсе штп урам-юл челтәре буенча хәрәкәт итүче йөк транспорты өлеше шактый зур;

- халыкның юлларда үз-үзен тоту культурасының тиешле дәрәҗәдә булмавы;

- машина йөртүчеләрне әзерләүнең түбән сыйфаты. Бу юл хәлен бәяләүдә ялгышларга китерә, дисциплинаның түбән булуы, юл хәрәкәтендә катнашучыларның (бигрәк тә яшьләрнең) дорфалыгы һәм җавапсызлыгы, транспорт чаралары белән идарә иткәндә машина йөртүчеләрнең игътибарсызлыгы һәм ваемсызлыгы ;

- юл хәрәкәте иминлеге буенча чараларны техник яктан тәэмин итүнең, беренче чиратта, юл хуҗалыкларының, транспорт чараларының, юл хәрәкәтен оештыру чараларының заманча таләпләргә туры килмәве, юл-транспорт һәлакәтләрен вакытында ачыклауга һәм зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтүнең элемтә системаларында артта калуы.

Аварияга бәйле катлаулы хәл һәм вәзгыятьнең алга таба начарлануына тенденцияләр булу күп очракта түбәндәге сәбәпләр белән аңлатыла:

- халыкның мобильлеге арта бара;

- җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүнең кимүе һәм шәхси транспортта пассажирлар йөртүнең артуы;

-автомобильләр саны арту һәм заманча транспорт агымнарына исәпләнмәгән

урам-юл челтәренең озынлыгы арасында диспорция арта баруы.

Мондый хәлләрнең нәтиҗәсе булып юл хәрәкәте шартларының начараюы, экологик хәлнең бозылуы, ягулык чыгымнарының артуы, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләренең саны арту тора.

Хәзерге вакытта торак пунктларда барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 70 проценттан артыгы була. Торак пунктларда юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләр саны арту темплары юл-транспорт һәлакәтләре санын арттыру темпларын узып китә.

Хәзерге заман юл-транспорт травматизмын анализлау күрсәткәнчә, юл-транспорт һәлакәтләрендә аеруча авыр тән җәрәхәтләре алучылар әкренләп арта бара. Мондый юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга медицина ярдәме күрсәтү эшен нәтиҗәсез оештыру алар арасында үлүчеләр саны күп булуының төп сәбәпләреннән берсе булып тора.

Соңгы елларда автопаркның тиз артуы һәм яңа машина йөртүчеләрнең һәм пассажир йөртүчеләрнең юл хәрәкәтенә күпләп кушылуы юл хәрәкәте шартларының үзгәрүенә китерде: транспорт агымнары тыгызлыгы артты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы юлларында хәрәкәт интенсивлыгы артты.

Урам-юл челтәренең үзгәрешсез геометрик параметрларында транспорт саны арту аларның гомуми үткәрүчәнлек сәләте сизелерлек кимүгә китергән. Бигрәк тә Балык бистәсенең Ленин, Совет, З.Шәймәрдәнов, Октябрь, Завод урамнарында Котлы Бөкәш авылының Үзәк, Ворошилов, Совет, Олы Елга авылының Чишмә урамында; Сабакай авылының Үзәк урамында; Анатыш авылының Үзәк урамында; Рус Әшнәге авылының Олимпия урамында хәрәкәт аеруча интенсив булып тора.

Мондый хәл юл-транспорт һәлакәтләренең барлык күрсәткечләрен даими кимүтү өчен тотрыклы шартлар тудырмый. Бу һәм башка каршылыклар юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль идарә системасын камилләштерү буенча комплекслы проблема булып торалар.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның максаты-гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы юлларында куркынычсыз хәрәкәт итү шартларына законлы хокукларының гарантияләрен арттыру.

Программаның максатларына ирешү шартлары булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:

- юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен куркыныч тотышын кисәтү;
- балалар катнашында юл-транспортта җәрәхәтләнү очракларын кимету, шул исәптән балалар катнашында да;
- транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү;
- юл хәрәкәтен көйләүнең заманча техник чараларын (светофорлар, юл билгеләре, тамгалар һ. б.) куллану.

Күрсәтелгән бурычларга ирешү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә авариялелек күрсәткечләрен киметергә һәм проблеманың социаль кискенлеген киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге программаны 1 ел дәвамында тормышка ашыру күздә тотыла.

Программада түбәндәге чараларны тормышка ашыру планлаштырылган:

- юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;
- балаларның юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау;
- чокырларны ремонтлау;
- ясалма юл тигезсезлекләрен урнаштыру;
- юл билгеләрен урнаштыру, хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- җәяүлеләр кичү юлларын һәм тамгаларны этаплап норматив таләпләргә китерү.

## III. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Программа төрле чаралар комплексын үз эченә ала.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын арттыруга һәм үз-үзләрен н юлларда куркыныч тотуны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар программаның **3 нче кушымтасында** китерелгән.

Чараның төп максаты-шәхес формалашу этабында, ягъни гомуми белем бирү оешмаларында юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен хәвефле тотышын кисәтү.

Проектта юл хәрәкәтендә аеруча саклanмаган катнашучылар буларак балаларга һәм яшүсмерләргә зур игътибар бирелә..

Район Башкарма комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча ЮХИДИ бүлеге белән берлектә, «Светофор», «Куркынычсыз тәгәрмәч», «Әгәр дә юл хәрәкәте кагыйдәләрен белсәң-ЮХИДИ белән проблема юк» һ. б. балалар өчен юл – транспорт имгәнүләрен кисәтү буенча чаралар үткәрү планлаштырыла.

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль бюджет учреждениесендә барлык белем бирү оешмаларында ЮИД отрядларын формалаштыру һәм балаларның юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү буенча район чаралары, «Светяшкалар», «Куркынычсыз зебра», «Яктырып тор», «Беренче сыйныф укучысына мәктәпкә куркынычсыз килергә ярдәм ит!" акцияләре үткәрү каралган. Башлангыч сыйныф укытучыларының һәм тормыш иминлеге нигезләре укытучыларының квалификациясен күтәрү; башлангыч сыйныф һәм тормыш иминлеге нигезләре укытучылары өчен укучыларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү методикасы буенча семинарлар оештыру; балалар юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау буенча ата-аналар өчен киңәшмә оештыру; мәктәп, шәһәр (район) балалар рәсемнәре конкурслары оештыру, мәктәп яны ял лагерьларына юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларын оештыруда методик ярдәм күрсәтү.

Ата-аналарның игътибарын балалар травматизмы проблемасына җәлеп итү өчен массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеге мәсьәләләрен даими

яктырту күздә тотыла. Контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, урам-юл челтәрен юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фото-видеофиксацияләү комплекслары белән алга таба җиһазландыру планлаштырыла.

Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру – планлаштыру һәм инженерлык чаралары Программаның **4 нче кушымтасында** китерелгән.

## IV. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

Программаны финанслауның гомуми күләме 209 680,46 мең сум, җирле бюджет хисабына 550 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау күләме юнәлешләр буенча программага **5 нче кушымтада** китерелгән.

Программаны финанслау күләме барлык чыганаклардан программага **6 нчы кушымтада** китерелгән.

Программа заказчылары арасында акчаларны бүлү программага **7 нче кушымтада** китерелгән.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм реаль мөмкинлекләрдән чыгып төгәлләштерелергә тиеш.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программа чараларын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты (килешү буенча) һәм Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә хуҗалык итүче субъектлар һәм Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык итүче субъектлар арасында гамәлдәге законнар нигезендә контрактлар нигезендә гамәлгә ашыру күздә тотыла.

Программаны тормышка ашыру эшчәнлеген координацияләүне район Башкарма комитеты башкара.

Программаны тормышка ашыру белән нәтиҗәле идарә итү буенча бурычларны хәл итү идарә итү рәвешләрен һәм методларын нигезле сайлап алу юлы белән башкарылачак.

### Программаны тормышка ашыру белән идарә итүнең оештыру-хокукый аспектлары

Программаны тормышка ашыру белән идарә итүне район Башкарма комитеты башкара.

Программаның җитәкчесе-район Башкарма комитеты җитәкчесе, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе рәисе.

Программа заказчыларының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе гамәлгә ашыра.

Программаны тормышка ашыру белән агымдагы идарәне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе рәисе башкара.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе түбәндәге төп функцияләрне тормышка ашыра:

- Программа чараларын тормышка ашыру турында статистик һәм аналитик мәгълүмат җыю һәм системалаштыру;
- Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләренә мониторинг, күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру турында аналитик мәгълүмат формалаштыру һәм Программаны тормышка ашыру турында хисап әзерләү;
- Программа чараларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен һәм аларның индикаторларга һәм программа күрсәткечләренә туры килүен бәйсез бәяләүне оештыру;
- Программаны тормышка ашыру барышы һәм нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
- башка функцияләр.

## Программаны тормышка ашыруны идарә итүнең финанс аспектлары

Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет һәм бюджеттан тыш башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла.

Район Башкарма комитеты ел саен финанслау объектларының адреслы исемлеген билгели.

Программаның гамәлдә булу туктатылуы - аны гамәлгә ашыру тәмамланган очракта, ә Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм район Башкарма комитеты карарлары нигезендә аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәсез дип танылган очракта, вакытыннан алда туктатыла.

Проектны тормышка ашыру өчен җаваплы район Башкарма комитеты, районның юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча).

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына
1 нче кушымта

ПРОГРАММА-МАКСАТЧАН МЕТОД БУЛМАУ ШАРТЛАРЫНДА АВАРИЯЛЕЛЕКНЕҢ КӨТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

| Күрсәткечләр | 2012 ел | 2025 ел |
|---|---|---|
| Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган кешеләр саны, кеше | 7 | 6 |
| Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган кешеләр саны, кеше | 34 | 29 |

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына
2 нче кушымта

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасы

КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕНӘ ИРЕШҮНЕҢ КӨТЕЛГӘН ДИНАМИКАСЫ

| Күрсәткечләр | 2025 ел | 2012 ел (отчет) |
|---|---|---|
| Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затларның потенциаль санын киметү (2012 ел белән чагыштырганда), кеше | -1 | 7 |
| Зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләренең саны кимү (2012 ел белән чагыштырганда), берәмлекләр | -5 | 34 (факт) |

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына 3 нче кушымта

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын арттыруга һәм үз-үзләрен куркыныч тотуларын кисәтүгә юнәлдерелгән
ЧАРАЛАР

| №№ п/п | Чараларның исеме | Үтәү вакыты | Финанс-лау күләме, (мең сум) | шул исәптән. (мең сум) | | | Үтәү өчен җаваплылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюд-жеты хисабы-на | ТР бюд-жеты хисабы-на | бюд-жеттан тыш чыганак лар хисабы-на | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Башка хаҗәтләр | | | | | | | |
| 1 | Һәр гомуми белем бирү учреждениесенең юл куркынычсызлыгы Паспортын ел саен яңарту | 2025 ел | - | - | - | - | "Мәгариф бүлеге» МКУ, Балык Бистәсе муниципаль районы гомуми | Һәр белем бирү учреждениесендә юл хәрәкәте куркынычсызлыгы почмагы булдыру |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Барлык белем бирү оешмаларында ЮИД отрядларын формалаштыру һәм аларның эшен оештыру. | | | | | | белем бирү оешмалары,<br><br>ЮХИДИ бүлеге хезмәткәрләре,<br><br>ДОСААФ,<br><br>Балык Бистәсе һәмПитрәч районнары буенча юл хәрәкәте куркынычсызлыгы идарәсе (килешү буенча)<br><br>Балык Бистәсе муниципаль районы мәгариф оешмалары | |
| 3 | Юл - транспорт имгәнүләрен профилактикалау буенча ата-аналар өчен стендны рәсмиләштерү, аларны системалы яңарту. | | | | | | | |
| 4 | Мәктәп директорлары, мәгариф учреждениеләре мөдирләре, педагогик Советлар, ата-аналар җыелышлары киңәшмәсендә БДД һәм ДДТТНЫ кисәтү мәсьәләләре буенча фикер алышу. | | | | | | | |
| 5 | ЮХИДИ бүлеге вәкилләре һәм инспекторлары катнашында гомуми ата - аналар җыелышы (баланы йөртү кагыйдәләре турында сөйләү, балаларның киемен яктылык кайтаргыч материаллардан торган элементлар белән җиһазландыру, шулай ук ата-аналар тарафыннан яктылык кайтаручы җайланмалардан файдалануны контрольдә тоту буенча аңлату эшләре алып бару; балаларны салонда куркынычсызлык каешын һәм балалар өчен тотып тору җайланмаларын мәҗбүри куллану мәсьәләләре). | | | | | | | Балаларда урамнарда һәм юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту күнекмәләрен үстерү |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | ЮХИДИ бүлеге вәкилләре һәм инспекторлары катнашында район мәктәпләрендә гомуми линейкалар | | | | | | | |
| 7 | ЮХИДИ хезмәткәрләре балигъ булмаганнар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре фактлары буенча тикшерүләр үткәргәндә, җаваплы мәгариф хезмәткәрләренә юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү чараларын эшләүдә катнашырга.<br>Педагогик хезмәткәрләр белән киңәшмәләрдә һәм ата-аналар җыелышларында тикшерүләр үткәрү нәтиҗәләрен җиткерергә. | | | | | | | |
| 8 | Мәгариф учреждениеләрендә балаларга юл хәрәкәте кагыйдәләрен укыту буенча инспекция үткәрүне оештыру. | | | | | | | |
| 9 | БДД буенча чаралар оештыруда мәктәп яны ял лагерьларына методик ярдәм күрсәтү. | | | | | | | Транспорт культурасы нигезләренә өйрәтү. Юл хәрәкәтендә катнашучыларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту стереотипларын формалаштыру |
| 10 | ЮХИДИ хезмәткәрләре көне-07 июль | | | | | | | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч сыйныфларда юл йөрү кагыйдәләрен мәҗбүри өйрәнүнең |
| 11 | «ТР Балык Бистәсе муниципаль районы урамнарда һәм юлларда балаларның иминлеген тәэмин итү " район семинар – практикумы | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | . | | | | | | тулы бер системасын булдыру |
| 12 | Балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү буенча район чаралары, акцияләр үткәрү:<br>"Куркынычсыз зебра",<br>"Яктылык",<br>"Куркынычсыз зебра",кучысына мәктәпкә куркынычсыз килергә ярдәм ит!" һ. б. | | | | | | |
| 13 | Фотоконкурс «Күренеп тор! Каешны каптыр һәм елмай.» Яктылык кайтаргыч куллануны профилактикалау | | | | | | Балалар катнашында юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау |
| 14 | Балаларны юл йөрү кагыйдәләрен белү конкурсларында һәм онлайн-олимпиадаларда катнашуга системалы һәм планлы әзерләү:<br>- "Светофор - безнең иң яхшы дустыбыз»,<br>- "Светофор»,<br>- "Куркынычсыз тәгәрмәч» | | | | | | |
| 15 | - "Яшел ут" мәктәпкәчә балалар учреждениеләре арасында район конкурсын оештыру һәм үткәрү. | | | | | | Укучыларны белем бирү оешмаларына куркынычсыз юллар маршрутында урнашкан урам объектларына игътибар итәргә өйрәтү . |
| 16 | «ЮИДның иң яхшы отряды һәм ЮИД отрядының иң яхшы җитәкчесе» республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Белем бирү оешмаларында юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнү буенча балалар белән эшне оештыру өчен методик кулланмалар рәсмиләштерү. | | | | | | |
| 18 | Иң яхшы Яңа ел уенчыгы конкурсы: "Яңа ел чыршысында юл билгесе". | | | | | | |
| 19 | Юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча иҗади эшләр күргәзмәсе:<br>* "Олы җәяүлеләр балалар күзлегеннән»,<br>*"Кышкы юл һәм без»,<br>* "Юл кагыйдәләрен балаларга белергә кирәк" һ. б. | | | | | | Транспорт культурасы нигезләренә өйрәтү. Юл хәрәкәтендә катнашучылар арасында куркынычсызлык стереотиплары формалаштыру. |
| 20 | - Рәсем күргәзмәсе:<br>* "Минем дустым-светофор»,<br>* "Юл хәрәкәте кагыйдәләрен белсәң - ЮХИДИ белән проблема юк»,<br>* "Юл уен урыны түгел»,<br>* » Мин – белемле җәяүле " һ. б. | | | | | | |
| 21 | - Куркынычсызлык айлыгы;<br>- Куркынычсызлык атналары кысаларында чаралар | | | | | | |
| 22 | «Игътибар-балалар! " профилактик операциясе вакытында чаралар оештыру һәм үткәрү | | | | | | Юлда куркынычсызлык проблемасына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү.<br>Юлларда хокукый грамоталылыкны, машина йөртү |
| 23 | "Бөтендөнья юл-транспорт һәлакәтләре корбаннарын искә алу көне " кысаларында чаралар | | | | | | |
| 24 | Кече яшьтәге балалар белән җәяүле экскурсияләрдә катнашу::<br>* "Автобус", | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | * "Күренеп тор!»<br>* "Яктыртып тор»,<br>* "Беренче сыйныф укучысына юлны үтәргә ярдәм ит»,<br>* "Куркынычсыз зебра " башлангыч сыйныф укучылары белән хәрәкәт схемаларын практик өйрәнү һәм юлда куркынычсыз тәртип күнекмәләрен конкрет шартларда куллану.<br>Әлеге эшне башкарганда юл куркынычсызлыгы паспортында күрсәтелгән хәрәкәт маршрутларына аерым игътибар бирергә кирәк. | | | | | | культурасын арттыру. |
| 25 | Белешмәлек тарату<br>- Ата-ана, машина йөртүче, онытма!»<br>- "Балаларны йөртү кагыйдәләре» | | | | | | |
| 26 | Район конкурсын оештыру һәм үткәрү | | | | | | Балалар бакчасында һәм мәктәптә юл йөрү кагыйдәләре буенча профилактик эшне камилләштерү. |
| 27 | Балалар юл-транспорт травматизмы, юлларда куркынычсыз тәртип, ата-аналар-шоферлар темасына мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында сыйныф сәгатьләре, әңгәмәләр, сыйныфтан тыш чаралар, дәресләр уздыруны дәвам итәргә, балигъ булмаганнар катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-пропаганда чараларын үткәрүне дәвам итәргә. | | | | | | Мәктәпкәчә белем бирү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Кече мәктәп укучылары белән һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә (алга таба мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә) мультфильмнар карау:<br>* "Юлда аю баласы" ,<br>* " Лунтик кагыйдәләрне өйрәтә»,<br>* Зай һәм Чик»,<br>* «Зебра баласының кышкы мажаралары»,<br>* «Степа абый"»,<br>* «Шук гаилә – хәрәкәт кагыйдәләре ("Белка һәм Стрелка " мультфильмыннан»),<br>* "Робокар Поли-юл йөрү кагыйдәләре" машиналары турында мультфильм сериясе» ,<br>* "Аркадий Паровозов ярдәмгә ашыга" һ. б. | | | | | | учреждениеләрендә, бигрәк тә башлангыч сыйныфларда юл йөрү кагыйдәләрен мәҗбүри өйрәнүнең тулы бер системасын булдыру. |
| **29** | Светофор турында нәфис әдәбият уку, картиналар, иллюстрацияләр карау, шигырьләр өйрәнү. | | | | | | |
| 30 | - Дидактик уеннар:<br>* "Светофор җый"»,<br>*«Машиналар һәм светофор»,<br>*"Урамны бизә" һ. б.<br><br>Ситуацияләрдән чыгу, юл йөрү кагыйдәләре буенча табышмакларга җаваплар бирү, сюжетлы-рольле уеннар: | | | | | | |

| | |
|---|---|
| | * «Без урамнан барабыз»,<br>* «Без-җәяүлеләр»,<br>* "Әгәр ... үзеңне ничек тотарга?" һ. б. |
| 31 | ТР буенча БДД идарәсе, район ЮХИДИ идарәсе тарафыннан балалар һәм ата-аналар белән САКЛА сайтыннан видеофильмнар һәм гыйбрәтле роликлар карау. |

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына 4 нче кушымта

Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән
ОЕШТЫРУ-ПЛАНЛАШТЫРУ ҺӘМ ИНЖЕНЕРЛЫК ЧАРАЛАРЫ

| №№ п/п | Чараларның исеме | Үтәү вакыты | Финанслау күләме, (мең сум) | Шул исәптән (мең сум) | | | Җаваплы башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | МБ бюд-жеты хисабына | ТР бюд-жеты хисабы -на | бюд-жеттан тыш чыганак-лар хисабына | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | Капиталь салымнар | | | | | | | |
| 1 | Анатыш авылы, Сергеев ур. ЩПСтан юл салу | 2025 год | 6 668,75 | 6 668,75 | - | - | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча | Юл хәрәкәте иминлеген арттыру |
| 2 | Балык Бистәсе, А. Меркушев ур.ЩПСтан юл салу. | | 687,5 | 687,5 | - | - | | |
| 3 | Балык Бистәсе, Сибгатуллин тыкрыгына ЩПСтан юл салу | | 5 775,0 | 5 775,0 | - | - | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Балык Бистәсе, Әхмәтҗанов ур. (подстанциягә керү юлы) ЩПСтан юл салу. | | 2750,0 | 2 750,0 | - | - | |
| 5 | Полянка авылы, Мелиоративная ур. юлларына асфальт җәю | | 6 030,00 | 6 030,00 | - | - | |
| 6 | Күгәрчен авылы, Заитовлар ур. юлларына асфальт салу | | 8 550,00 | 8 550,00 | - | - | |
| 7 | Урахча авылы юлына асфальт җәю (мәктәпкә керү юлы) | | 6 440,00 | 6 440,00 | - | - | |
| 8 | Балык Бистәсе штп,Совет урамындагы юлга асфальт салу. | | 10 800,00 | 10 800,00 | - | - | |
| 9 | Балык Бистәсе штп Октябрь урамындагы юлга асфальт түшәмә салу. | | 1 350,00 | 1350,00 | - | - | |
| 10 | Балык Бистәсе штп Победа урамындагы юлга асфальт түшәмә салу. | | 4950,00 | 4950,00 | - | - | |
| 11 | Балык Бистәсе штп Тукай урамындагы юлга асфальт салу | | 2 610,00 | 2 610,00 | - | - | |
| 12 | Балык Бистәсе штп. юл билгеләре салу. | | 3 000,00 | 3 000,00 | - | - | |
| 13 | Балык Бистәсе штп. да чокырларны ремонтлау | | 2 000,00 | 2 000,00 | - | - | |
| 14 | .Полянка, Центральная ур. (тротуар) | | 7 200,00 | 7 200,00 | - | - | |
| 15 | Балык Бистәсе штп да тукталыш урыны җиһазлау | | 2 550,00 | 2 550,00 | - | - | |
| 16 | Балык Бистәсе штп Ленин урамындагы юлга асфальт түшәмә салу. | | 24 885,00 | 24 885,00 | - | - | |
| 17 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлегендә урам-юл челтәре участокларын барьер киртәләре белән җиһазлау | | 903,483 | 903,483 | - | - | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Бикчурай авылында М. Горький урамында ясалма тигезсезлек урнаштыру | | 159,097 | 159,097 | - | - | | |
| 19 | "Күки гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ янындагы БДБ комплексы | | 318,17 | 318,17 | - | - | | |
| 20 | Балык Бистәсе штп М.Гыйззәтуллин урамында ясалма тигезсезлек урнаштыру. | | 159,086 | 159,086 | - | - | | |
| 21 | Октябрь урамындагы БДД комплексы (Идеал кибете янында) | | 318,17 | 318,17 | - | - | | |
| 22 | Балык Бистәсе ш.т.п Сөембикә урамындагы юл-транспорт һәлакәте куркынычсызлыгы комплексы | | 318,17 | 318,17 | - | - | | |
| 23 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе штп да юл-урам челтәре төзелеше. | | 110 708,03 | - | 99637,23 | 11 070,8 | | |
| Башка хаҗәтләр | | | | | | | | |
| 4 | Тәрәк билгеләре, җәяүлеләр өчен юл кичүе билгеләре кую, юл билгеләрен ремонтлау һәм алыштыру, юлларда чокырларны ремонтлау, ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | 2025 год | 550,00 | 550,00 | - | - | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты, ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча) | ЮТҺ барлыкка килү куркынычын киметү |
| | Барлыгы | | **209 680,46** | **98972,53** | **99 637,23** | **11 070,7** | | |

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына 5 нче кушымта

«2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын җирле бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклардан юнәлешләр буенча

ФИНАНСЛАУ КҮЛӘМНӘРЕ

(тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып, мең сум акча каралган)

| Күрсәткечләр | 2025 ел | Муниципаль берәмлек бюджеты средстволары | | | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Бар-лыгы | НИОКР | Капи-таль кертем-нәр | башка хаҗәт-ләр | НИОКР | Капи-таль кертем-нәр | башка хаҗәт ләр | НИОКР | капиталь кертем-нәр | башка хаҗәт-ләр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Хокукый аңны арттыру һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен куркыныч тотышын кисәтү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары | 209 680,46 | - | 93 422,43 | 5 550,00 | - | - 99637,23 | - | - | 11 070,8 | - |

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына
6 нче кушымта

«2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын җирле бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына статьялар буенча
ФИНАНСЛАУ КҮЛӘМНӘРЕ

| Финанслау чыганаклары | 2025 год |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек бюджеты средстволары– барлыгы, шул исәптән: | 98 972,53 |
| капиталь кертемнәр | 93 422,43 |
| башка хаҗәтләр | 5 550,00 |
| Татарстан Республикасы бюджеты средстволары – барлыгы, шул исәптән: | 99637,23 |
| капиталь кертемнәр | 99637,23 |
| башка хаҗәтләр | - |
| Бюджеттан тыш чыганаклар средстволары– барлыгы, шул исәптән: | 11 070,8 |
| капиталь кертемнәр | 11 070,8 |
| башка хаҗәтләр | - |
| Барлык чыганаклардан Программаны финанслау күләме | 209 680,46 |

“2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" муниципаль программасына 7 нче кушымта

Программаның заказчылары арасында "2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру” муниципаль программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән

СРЕДСТВОЛАРНЫ БҮЛҮ

(тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып, мең сум акча каралган)

| Программа заказчылары | 2025 ел барлыгы | Капиталь кертемнәр | Башка хаҗәтләр |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты | 98 972,53 | 93 422,43 | 5 000,00 |
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты. | 550,00 | - | 550,00 |
| Татарстан Республикасы | 20 923,82 | 20 923,82 | - |
| Россия Федерациясе | 78 713,41 | 78 713,41 | - |
| "КАМА" кулланучылар җәмгыяте | 11 070,8 | 11 070,8 | - |
| Барлыгы: | 209 680,46 | 204 130,46 | 5550,00 |